Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының
Совхозно-Галактионовский авыл җирлеге башлыгы
Карары

2020 елның 30 октябре №7

«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Чистай муниципаль районы Совхозно-Галактионовский авыл җирлегенең Фиков-Колок авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Чистай муниципаль районының «Совхозно-Галактионовский авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2020 елның 25 ноябрендә 14.00 сәгатькә үзәк мәйданда Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Совхозно-Галактионовский авыл җирлегенең Фиков-Колок авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Фиков-Колок авылы, Нагорная ур.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:
«2021 елда Чистай муниципаль районы Совхозно-Галактионовский авыл җирлегенең Фиков-Колок авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән үзара салым кертүгә, 100 сум күләмендә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризалашасызмы:
- авыл эчендәге чокырлы юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, китерү, салу, килешү буенча түләү)

« РИЗА» «КАРШЫ».

3. Җыенны оештыручы итеп Чистай муниципаль районының Совхозно-Галактионовский авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.
4. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләрне күпләп җыелган урыннарда, игълан итү стендларында һәм такталарында элү юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Чистай муниципаль районының
Совхозно-Галактионовский
авыл җирлеге башлыгы ________ В.Л.Донеев